**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

2016 ел, 15 апрель

№ 230

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт автоном учреждениесен бетерү турында» 2015 ел, 31 июль, 555 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан картлар һәм инвалидлар интернат йорты» социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт автоном учреждениесен бетерү турында» 2015 ел, 31 июль, 555 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктта «Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына» сүзләреннән соң «, «Костер» өстәмә белем бирүче республика дәүләт бюджет учреждениесенә» сүзләрен өстәргә;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына «2016 елга Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2015 елның 20 ноябрендәге 97-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына тиешле үзгәрешләрне кертү хакында тәкъдимнәр әзерләргә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына кертергә.»;

түбәндәге эчтәлекле яңа 4.1 пункт өстәргә:

«4.1. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинетының «2016 елга Татарстан Республикасы социомәдәни тармагының аерым дәүләт учреждениеләре норматив чыгымнарын раслау турында» 2015 ел, 20 ноябрь, 880 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында карар проектын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков